**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Акбаш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**
Акбаш ав.

№11 31.05.2018 ел

***Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының Нигезләмәсенә өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертү турында***

*2017 елның 5 декабрендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешмалар һәм медик - социаль экспертиза федераль учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләүне үткәрүне камилләштерү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 392-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә,*
Акбаш авыл җирлеге Советы

К А Р А Р И Т Т Е:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниөипаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

3.2 пунктының 13 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

- федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрүне контрольдә тоту;"

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: www.yutaza.tatar.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы: Л.Р.Тимербаева